# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның $2^1$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$2^1$. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары, депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, әлеге статьяның 1 пунктында һәм 2 пунктының "б" пунктчасында каралган нигезләр буенча кабул ителә, әгәр бу нигез Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре арасында барлыкка килсә, – шушы нигез барлыкка килгән көннән өч айдан да соңга калмыйча.";

2) 6 статьяда:

а) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Бу чакта кандидатларның Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән һәрбер исемлеге составында сайланган кимендә бер депутатка һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган һәр депутатка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә депутат эшчәнлеген даими профессиональ нигездә башкару хокукы бирелә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

"$3^1$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның һәрбер исемлеге составында сайланган, шулай ук Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган депутатларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында җитәкче вазыйфаларны биләү хокукы бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында җитәкче вазыйфалар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе вазыйфалары була.";

3) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3. Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган депутатка фракцияләр вәкилләре белән бертигез дәрәҗәдә түбәндәге хокуклар бирелә: Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлана торган вазыйфаларга кандидатлар тәкъдим итү; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында чыгыш ясау; материалларны һәм документларны алу һәм тарату; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы эшендә катнашу. Әлеге хокукларны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.";

4) $7^1$ статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлеге составында сайланган депутатлар, әлеге статьяның 7 пунктында каралган очрактан гайре, депутат берләшмәләренә (алга таба – фракцияләр) керәләр. Фракция кандидатларның депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән тиешле исемлеге составында сайланган депутатларны (депутатны) үз эченә ала. Фракцияләргә шулай ук бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партияләрнең кандидатлары исемлекләре составында сайланган депутатлар да керергә мөмкин.";

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның республика исемлекләре составында сайланган депутатлар, шулай ук әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партияләр кандидатларының республика исемлекләре составында сайланган депутатлар фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре төзергә хокуклы.";

в) 5 пунктта "сәяси партия кандидатларының республика исемлеге" сүзләрен "тиешле сәяси партия кандидатларының республика исемлеге" сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктта "сәяси партия кандидатларының республика исемлеге" сүзләрен "тиешле сәяси партия кандидатларының республика исемлеге" сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^{1}$ статьясы нигезендә кандидатларының республика исемлегенә депутат мандаты тапшырылган сәяси партия бетерелүгә яисә үзгәртеп корылуга бәйле рәвештә аның эшчәнлеге туктатылган очракта, мондый сәяси партия кандидатларының республика исемлеге составында сайланган депутат фракция вәкилләре белән бертигез дәрәҗәдә бирелгән хокукларын юридик затларның бердәй дәүләт реестрына тиешле язма ясалган көннән югалта. Шул көннән мондый депутат, әлеге статьяның 5 пунктында каралган таләпләрне үтәгән килеш, теге яисә бу фракциягә керергә хокуклы.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 6, 7 һәм $7^{1}$ статьялары нигезләмәләре (фракциянең кандидатларның депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән тиешле исемлеге составында сайланган депутатларны (депутатны) үз эченә алуын күз алдында тота торган нигезләмәдән гайре) әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң билгеләнгән сайлауларда сайланган чакырылышларның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 86-ТРЗ